МИНИСТЕРСТВО
ЛЕСНОГО ХОЗЯЙСТВА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
УРМАН ХУҖАЛЫГЫ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

21.10.2024 № 392-осн

Казан ш.

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгында вазыйфаи бурычларны үтәү дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләрдән файдалануга бәйле булган, вазыйфага билгеләнгәндә конкурс уздырылмаска мөмкин булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында» 2019 елның 8 апрелендәге 246-осн номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы норматив хокукый актын законнарга туры китерү максатларында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгында вазыйфаи бурычларны үтәү дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләрдән файдалануга бәйле булган, вазыйфага билгеләнгәндә конкурс уздырылмаска мөмкин булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында» 2019 елның 8 апрелендәге 246-осн номерлы боерыгына (Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының 2019 елның 11 июнендәге 583-осн номерлы, 2023 елның 18 апрелендәге 206-осн номерлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы федераль законның 22 статьясындагы 3 өлеше, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе вазыйфаи затларын һәм гражданнарын дәүләт серенә кертү кагыйдәләрен раслау турында» 2024 елның 7 февралендәге 132 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясе гражданнарын һәм вазыйфаи затларын дәүләт серенә кертү кагыйдәләре нигезендә боерык бирәм:»;

Әлеге боерык белән расланган Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгында вазыйфаи бурычларны үтәү дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләрдән файдалануга бәйле булган, вазыйфага билгеләнгәндә конкурс уздырылмаска мөмкин булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә).

2. Юридик бүлек җитәкчесенә (Т.А.Барсукова) боерык имзаланган көннән башлап эш көннәрендә исәпләнгән өч көнлек чорда аны, дәүләт теркәвенә алу өчен, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

3. Бу боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Министр Р.Ә.Кузюров

Татарстан Республикасы
Урман хуҗалыгы
министрлыгының 2019 елның
8 апрелендәге 246-осн номерлы
боерыгы белән расланды
(2024 елның 21 октябрендәге
392-осн номерлы боерык
редакциясендә)

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгында вазыйфаи бурычларны үтәү дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләрдән файдалануга бәйле булган, вазыйфага билгеләнгәндә конкурс уздырылмаска мөмкин булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеге

1. Татарстан Республикасының «җитәкчеләр» категориясендәге граждан хезмәтенең баш вазыйфаларын биләүче дәүләт граждан хезмәткәрләре:

эшләр идарәчесе;

финанс, бухгалтерлык исәбе һәм контрольлек бүлеге башлыгы;

юридик бүлек җитәкчесе;

икътисад, дәүләт заказын урнаштыру һәм түләүләр белән идарә итү бүлеге җитәкчесе;

урманнарны торгызу һәм урманнарны үрчетү бүлеге башлыгы;

аренда мөнәсәбәтләре бүлеге башлыгы;

дәүләт контроле һәм күзәтчелеге бүлеге җитәкчесе;

дәүләт урман реестры, урманнардан файдалану һәм урман корылышы бүлеге җитәкчесе;

мөлкәт белән идарә итү, техник үсеш һәм хезмәтне саклау бүлеге җитәкчесе;

оештыру эшләре бүлеге җитәкчесе.

2. Татарстан Республикасының «җитәкчеләр» категориясендәге граждан хезмәтенең әйдәп баручы вазыйфаларын биләүче дәүләт граждан хезмәткәрләре:

дәүләт хезмәте һәм кадрлар мәсьәләләре секторы мөдире;

урман фондын саклау секторы мөдире;

мәгълүмат технологияләрен үстерү секторы мөдире;

финанс, бухгалтерлык исәбе һәм контрольлек бүлеге җитәкчесе урынбасары;

икътисад, дәүләт заказын урнаштыру һәм түләүләр белән идарә итү бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе;

дәүләт хезмәте һәм кадрлар мәсьәләләре секторының әйдәп баручы консультанты;

мәгълүмат технологияләрен үстерү секторының әйдәп баручы консультанты.

3. Татарстан Республикасының «белгечләр» категориясендәге граждан хезмәтенең әйдәп баручы вазыйфаларын биләүче дәүләт граждан хезмәткәрләре:

әйдәп баручы консультант (мобильләштерелгән эш һәм дәүләт серен саклау буенча белгеч).